КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 ноябрь г.Казань № 974

«Миңлебай – Казан» магистраль этанүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының линия объектын эксплуатациясе максатларында гавами сервитут урнаштыру турында

Россия Федерациясе Җир кодексының V$^{7}$ бүлеге, 2009 елның 22 июнендәге 16-АБ серияле 203692 номерлы хокукны дәүләт теркәве турында таныклыкка ярашлы рәвештә, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең (ИНН 1600000036, ОГРН 1021603624921) үтенече нигезендә, «Миңлебай – Казан» магистраль этанүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының линия объектын эксплуатацияләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Миңлебай – Казан» магистраль этанүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының линия объектын эксплуатацияләү максатларында кушымта нигезендә җирләргә һәм җир кишәрлекләренә (алга таба – җир кишәрлекләре) карата 49 елга гавами сервитут билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Миңлебай – Казан» магистраль этанүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының линия объектын эксплуатацияләү максатларында гавами сервитут чикләре урынының график тасвирламасы (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Алексеевск, Югары Ослан, Зеленодольск, Лаеш, Питрәч муниципаль районнары территорияләрендә);

«Миңлебай – Казан» магистраль этанүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының линия объектын эксплуатацияләү максатларында гавами сервитут чикләре урынының график тасвирламасы (Әлмәт, Яңа Чишмә, Чистай муниципаль районнары территорияләрендә).

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

гавами сервитут иясе – «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

гавами сервитут өчен түләүне исәпләү һәм кертү тәртибе Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{46}$ статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарның күчермәләрен «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә җибәрүне.

5. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән гавами сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзүне;

җир кишәрлекләрен алардан рөхсәт ителгән файдалануның төре нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясындагы 8 пунктында билгеләнгән вакытта файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне;

гавами сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясындагы 8, 9 пунктларында билгеләнгән срокларда сүтүне.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин